

ISSN 0868-4545

Салават күпере



Кышкы әкият


Кыш көне булган бу хәл. Алсу чанасын алып урамга чыккан. Ябалак-ябалак кар ява башлагач, балалар өйләренә таралышкан. Алсу кар яуганга сокланып, берүзе басып калган. Шулвакыт аның тун җиңенә иң эре кар бөртеге килеп кунган.

– Син кем? – дип сораган Кар бөртеге кыздан.

– Мин Алсу, әнә теге йортта яшим. Син миңа бик ошыйсың, – дигән Алсу, Кар бөртегенең матурлыгына соклануын яшерә алмыйча.

– Син дә миңа ошыйсың, әйдә бергә уйныйбыз, – дигән Кар бөртеге.

Алар бергә бик озак таудан чана шуганнар, кар көртләрендә рәхәтләнеп аунаганнар, кычкырып-кычкырып көлгәннәр. Кинәт исеп киткән җил аларны бөтерелдереп күккә алып менеп киткән. Өстән караганда җир бик матур күренгән



Рәссам Фәридә ЗӨЛКАРНӘЙ

© "Салават күпере", 2002 ел

Алсуга. Җем-җем иткән, әле кер кунарга өлгермәгән ап-ак кар бөтен дөньяны каплап, аны саф һәм пакь итеп күрсәткән. Алсу белән Кар бөртеге шулкадәр дуслашканнар ки, эңгер-меңгер төшеп, йортларда утлар кабына башлагач та бер дә аерылышасылары килмәгән. Моңаеп калган Алсуга карап, Кар бөртеге:

– Борчылма, дустым, өеңә керүгә, мин эрергә өлгергәнче, рәсем дәфтәрен ач, шунда сакланырмын, – дигән.

Кар бөртеге Алсуның башлыгына ияреп кергән һәм кыз йөгереп барып рәсем дәфтәрен киштәдән алып ачуга, дәфтәр битенә очып төшеп, бизәк булып сеңгән.

Яз җитеп, башка кар бөртекләре гөрләвекләргә ияреп, елгаларга кушылып олы сәяхәтләргә ашыкканда да, дәфтәр битендәге Кар бөртеге Алсуга тугры булып калган. Җәйнең эссе көннәрендә кыз рәсем дәфтәрен еш кына ачып, андагы бизәккә караган. Кар бөртеге аңа матур итеп елмайган.



Чын дуслар белән уздырган рәхәт мизгелләр озак хәтердә саклана шул алар...

Эльвира ШӘРИПОВА



Кызыксыз арифметика



Укучым!

Без хата җибәрмәдек, сәхифәнең исемен махсус рәвештә: «Кызыксыз...» дип куйдык. Үзең аңлап, төшенеп җиткермәсәң, өлкәннәрне дә ярдәмгә чакыр, яме!

Октябрь аенда Рәсәйдә халык санын алу булып узды. Рәсәйдә яшәгән татарларның санын киметү өчен ни генә кыланмадылар. Сәхифә шуңа багышлана.

Мөхәммәт классьагы укучылар санын исәпләп, ничә милләт вәкиле барлыгын әйтергә тиеш. Класста барлыгы 20 укучы. Шуларның икесе типтәр, унбише мишәр, калган өчесе керәшеннәр. Класстагы балаларның ничәсе татар?

Җавап: һәммәсе дә татар балалары.



Унике себер татары, тугыз керәшен, тагын җиде кырым һәм биш казан татары Сабантуйга барырга җыена. Сабантуйга ничә татар барачак?

Җавабын үзең тап.

Казанда яшәүче бер татар гаиләсендә ике кыз, бер малай үсә. Әти-әниләре татарча бер авыз сүз белми боларның.

Бу гаиләдә ничә татар баласы бар?

Җавап: биш татар. Тик менә татарча белмәүләре генә кызганыч.

Башкортостандагы бик зур бер татар авылында биш мең татар кешесе яшәгән. Башка милләт булмаган. Халык санын алудан соң бу авылда ничә татар кешесе калган?

Җавап: бер татар да калмаган. Ә күктән биш мең башкорт иңгән. Алар аңарчы болытларга эленеп торган булганнар икән! Менә сиңа мә!

Рәссам Илдар НӘФИЕВ



Зиннур ХӨСНИЯР

Алмачуар әкияте

(Дәвамы. Башы 8-10 нчы саннарда.)

Кабан дуңгызлары Галишаһка биш олау урман печәне, бер амбар солы бирделәр. Ләкин хыянәтче Галишаһ моңа гына риза түгел иде әле. Алмачуарларның биләмәләренә хан буласы килде аның. Дуңгызлар аның һәр теләгенә каршы: «Баш өсте!» – дип тордылар, нәрсә тели шуны үтәргә әзер иде сугыш чукмарлары. Алмачуар биләмәсендә син хан булып торырсың, диделәр.

Алмачуарларның биләмәләре бик нык ныгытылган иде. Анда үтеп керү өчен яшерен капкаларны яхшы белергә кирәк иде. Галишаһ дошманга әнә шул капкаларның ачкычын бирергә уйлады.

Кабан дуңгызлары Алмачуар биләмәләреннән ерак түгел генә Галишаһ өчен гаскәр туплады. Үзе кебек сатлыкҗан алмачуарларны гаскәренә җыярга кереште.

«Дуңгызлар сугышка әзерләнә» дигән хәбәр алмачуарларга да килеп ишетелде. Алар кайгыга төштеләр, ләкин куркып калмадылар. Батыр иде алар, кыю иделәр. Әмма кабан дуңгызлары сан ягыннан ишле иде шул. Җитмәсә, сатлыкҗаннар да аларга кушылды.

Алмачуарларның туган тиешлеләре Җир шарының бүтән җирләрендә дә яшиләр иде. Мәсәлән, Кырымда – Кара диңгез буйларында, Әстерхан җирләрендә. Ләкин алар кабан дуңгызларына каршы туганнарын яклап көрәшмәделәр. Әгәр барысы бергә берләшсәләр инде шунда!..

Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ







Шәфкатьле бул, балам...

Саранга җәза

Гарәп хикәяте



Бер кечкенә авылда Хәлил исемле бик саран кеше яшәгән. Аның кибете булган. Авыл халкы шул кибеттән төрле кирәк-ярак, азык-төлек сатып алып көн иткән.

Кибетендәге һәр әйберне Хәлил кыйммәт хакка сатарга тырышкан. Бурычка сораганнарга ул «юк!» дип кенә җавап биргән.

Беркөнне кибеткә, күз яшьләренә буылып, Гали исемле малай килгән.

– Хәлил абый, әтием бик каты авырый. Ачтан интегәбез. Безгә бераз гына ризыклар биреп торалмассың микән? Әтием терелгәч, бурычны түләр иде, – дигән ул.

Хәлил, малайны бик яман ачуланып, «Бурычка бирмим! Акча алып кил!» – дип, кибетеннән төрткәләп чыгарган.

Икенче көнне Хәлил янына Ибраһим шәех белән берничә кеше килгән.

– Мәктәпне төзеп бетерергә акча җитмәде. Бераз ярдәм итмәссеңме? – дигәннәр алар.

Хәлилнең җавабы күптән әзер:

– Юк шул, акчам юк, – дигән ул, буш кесәләрен күрсәтеп.

Ибраһим шәех, саран кибетченең йөзенә туп-туры карап, Аллаһы Тәгаләнең сүзләрен кабатлаган: «Кем дә кем, алтын-көмешләргә ия булып та, аларны изге эшләргә сарыф итми икән, ул алдагы көннәрдә җәзасын алыр»...

Беркөнне кич, акчаларын яшереп тартмага куйган чакта, Хәлил ялгыш терсәге белән өстәлдәге кәрәчин лампасын аударган. Өстәлдәге эскәтергә, кәгазь акчаларга ут капкан. «Коткарыгыз! Ярдәм итегез!» – дип кычкырган Хәлил.

Авыл халкы, дәррәү килеп, утны сүндерергә керешкән. Әмма алар, ничек кенә тырышмасыннар, Хәлилнең кибетен уттан саклап кала алмаганнар.

Хәрабә тирәсендә «Акчаларым!.. Минем акчаларым!..» – дип кычкырып-җылап йөргән бичара Хәлилгә карап, берәү әйтеп куйган:

– Саран тиешле җәзасын алды...

Рәссам Иван ВОРОБЬЁВ









Әлеге матур-матур сурәтләрне Казандагы 90 нчы татар-рус мәктәбендәге рәсем түгәрәгенә (җитәкчесе Гүзәл Миңнулла кызы Гайнуллова) йөрүче балалар ясаган.




Гөлнара Нәҗмиева



Айсылу Гарипова



Венера Әбделмәнова



Алия Шәрипова



Олеся Давыдова

БАШВАТКЫЧ - РӘСЕМ



Ничәү без?

Мәтәлешеп калдык бар да –
Төшеп китте чанабыз...
Куып тотарга чананы
Юк шул инде чамабыз.

Әле анда, әле монда
Көрткә чумып калганбыз...
Йә, кем тизрәк саный ала –
Тауда ничә бала без?

Рәссам Алла АЙСИНА


Шәҗәрә

Журналыбызның алдагы санында Казанның 1000 еллыгы уңаеннан укучыларга мондый сораулар биргән идек:

Син җиде бабаңны беләсеңме?

Рәхимсез сугышта, ягъни моннан 450 ел элек, 1552 елда Казанны явыз дошманнардан саклаган вакытта синең кайсы бабаң кан койган?

Инде тәүге хатлар килә дә башлады.



(Дәвамы 15нче биттә.)

Минем әтием Рашат исемле. Әтиемнең әтисе Махмубрахман, ул минем бабакай, аның әтисе Насыйбулла, аның әтисе Хәмматҗан, аның әтисе Мәхмүт, аның әтисе Мәлик, аның әтисе Мөхәмматҗан булган.

Әтиемнең әнисе, минем әбекәй, Әлфә, әбекәйнең әтисе Мөхлисулла. Аның әтисе Гайнулла, аның әтисе Зәйнулла, аның әтисе Гаймулла, аның әтисе Нигъмәтулла, аның әтисе Газизулла, аның әтисе Рахманкол.

450 ел элек булган рәхимсез сугышта Рахманкол бабай белән Мөхәмматҗан бабай кан койган. Гражданнар сугышында Гайнулла бабай белән Самат бабай катнашкан. Мөхлисулла бабай 1941 елдан 1945 елның май аена кадәр Бөек Ватан сугышында булган.

Айрат САМАТОВ, 13 яшь. Зәй, Югары Ложы.

Рөстәм Мингалимнең балалар өчен язган китаплары

Әйт, кояшым	1966
Ә сәгать келт-келт итә	1968
Уйларга кирәк	1971
Төнге әкият	1973
Бәхетле исем	1977
Исәнме, әткәй	1979
Галстуклы кәҗә	1992
Голубое седло	1976
На лесной прогаленке	1980
Счастливое имя	1983
Растут мальчики	1985

Кадерле дуслар!

Журналның урта битен иплап кенә алып, кара сызыклар буенча кисегез, сары сызыклар буенча бөкләгез дә килеп чыккан кисәкләрне, бит саннарына карап, китап итеп җыегыз. Булгач-булгач, чын китап булсын — уртасын ике урыннан төпләп куегыз.

©«Салават күпере» китапханәсе.

Рәссам

Лилия Золондинова

Рөстәм МИНГАЛИМ


Колак сәгате

Атланырмын – ат бирсәң

Атланырмын – ат бирсәң,
Атта йөргән малай мин.
Сер сөйләсәң саклармын,
Саклый белгән малай мин.
Кылыч бирсәң алырмын,
Кылыч күргән малай мин.
Бабаларым канында –
Яуга кергән малай мин.
Ярасында солдатның –
Әрнеп барган малай мин.
«Ура!» тавышы булып,
Һава ярган малай мин.







Тизрәк үсәсең килсә, күбрәк укы. Уку сине уйландырыр, көлдерер. Үзеңне дә, акылыңны да тизрәк үстерер.


Рөстәм Мингалим

Ярдәмче чыпчык

Юл өстенә су җибәргән,
Язгы кояш авыз ерып.
Су янында соры чыпчык
Җырлап йөри чырык-чырык.
Марат кына мышык-мышык
Елап тора юл буенда:
«Үтеп булмас, су тирәндер,
Я билдән, ди, я муеннан.
Нишләргә соң?
Әбиләргә
Бара алмый калам инде...»
Сизде бугай
Соры җырчы –
Пырлап күккә күтәрелде.
Юл өстендә яткан суның
Уртасына кунды чыпчык:
– Кара, Марат, тирән түгел.
Курыкма, ди, әйдә, чык-чык.



Алма төшкән



Алма төшкән,
Тәгәрәп киткән.
Аны мәче
Куып җиткән.
– Кая киттең,
Кызыл алма? –
Дип сораган
Мәче аннан.
Тәгәрәүче
Эндәшмәгән,
Тәгәрәгән,
Алга киткән.
Һәм ул үзе –
Алма түгел,
Кызыл йомгак
Булган икән.







Колак сәгате

Стена сәгате була,
Кесә сәгате була,
Ә нигә булмасын, дим.
Кул сәгате дә була,
Аяк сәгате дә булыр,
Ә нигә булмасын, дим.
Колак сәгате дә булыр,
Ә нигә булмасын, дим.
Кызыл бозау колагына
Сәгать тагып куйдым мин.
Тау битенә менәрбез,
Вакытны да белербез.
Әниемнең кул сәгатен
Кайтарып та бирербез.
...Бозау, сәгать, мин –
Өчәү –
Әле бергә йөрибез.
Сәгать кебек
Йөрибез.


Кыюлык


Җыелдылар малайлар,
Чаңгы табып бирделәр:
– Без кыюны яратабыз,
Әйдә, шуыйк бер, – диләр, –
Шунысын да онытма,
Биек, – диләр, – тавыбыз.
Шуа белми шуганнарның
Җимергәли авызын!
– Егылу ул – кызык эш,
Егылу ул – шәп, димен.
Чаңгы шуа белмәвемне
Тегеләргә әйтмимен.
Менсәк тауның башына,
Калды башны кашырга.
Ничек кенә төшәргә соң,
Кем артына басарга?
Егылуың шәп эш тә,
Егылмавың да әйбәт:
Чаңгыларны кулга тотып,
Төшеп киттем җәяүләп.




Бала балык

Балык әйткән
Баласына:
– Әкрен уйна,
Иплəп уйна!
Бала балык
Тыңламаган,
И сикергән!
И уйнаган!
Сикереп ялгыш
Чыккан ярга –
Ярый яңгыр
Килеп җиткән,
Коеп яуган
Һəм коткарган.







Ак куян

Абыем каядыр җыена,
Мине генə ияртми.
– Җылы өйдə тыныч кына
Рəсем ясап утыр, – ди.
Иярт, абый, ни күрсəм дə,
Кайткач ясыйм дип əйттем.
Чаңгы такканымны көтте,
Абый мине ияртте...
Тик ерак бара алмадык.
Бер генə куян күрдек.
Борыным өши башлагач,
Əйлəнеп өйгə кердек...
Абыем: – Куян яса! – дип,
Өстəлгə кəгазь куя.
Ничек ясыйм ди инде мин
Ак кəгазьгə ак куян?!



Минем иң ерак бабам Габтулла исемле булган, аның улы Мәһмүт, Мәһмүтнең улы Шәмсетдин... (Шәмсетдин бабай бик ярлы кеше булганлыктан Киров өлкәсе Малмыж шәһәрендә яшәүче Кунаев дигән купецта хезмәтче булып эшләгән һәм шул чорда купецларга, муллаларга ялланып алты мәртәбә хаҗга барган. Шуннан кергән акча хисабына җиденче мәртәбә үзе өчен хаҗ кылган. Авылда аны Хаҗи бабай дип йөрткәннәр). Шәмсетдинның улы Гыйматдин, Гыйматдинның улы Мөхәммәтгали, Мөхәммәтгалинең улы – минем бабай – Фаварис исемле, аның улы Ленар исемле. Мин Ленарның улы Ранил булам.

Сугыш газапларын Гыйматдин улы Мөхәммәтгали күргән. Ул беренче мәртәбә 1914 елдагы патша сугышына чакырылган һәм анда үгез белән орудие йөрткән. Мөхәммәт бабам өченче мәртәбә икенче бөтендөнья сугышына чакырылып, сугышып, исән-сау туган авылы Смәелгә кайта. 1988 елда вафат булган бу бабабыз белән без бик горурланабыз.

Ранил Ленар улы **ГАЛИЕВ**, 11 яшь. Балтач, Смәел.

Рәссам Алла АЙСИНА

Азат ГӘРӘЕВ, 7 яшь.
Әтнә, Яңа Әтнә.

Казанның 1000 еллыгына.
Исәнмесез кадерле „Салават күпере" язучылар. Мин – Гарәев Азат Әтнәдә 1-Б классында укыйм. Сезнең журналны бик яратам, күптән алдырабыз.
Мин Сезгә үземнең дәү әтиемнең әтисе Салихов Нәҗип турында язасым килә. Карт бабам 1901 елда туган, ул Бөек Ватан сугышында батырларча һәлак булган. Нәҗип бабам бик яхшы, тырыш, акыллы кеше иде, дип сөйли дәү әтием. Авылымда Бөек Ватан сугышында үлгәннәргә һәйкәл куелган, анда ...нем. бабамның исеме бар.









– Физик күнегү ясыйбыз –
Башны артка ташладык.
Максатыбыз: табаннарга
Тидерергә башларны.

Мөслим, Урәзмәт.



– Машинага утырдык та
Килдек җилдереп кенә...
Инде җиргә төшергәнне
Көтеп торабыз менә!

Азнакай, Чубар Абдул.



– Бигрәк укырга ярата –
Курчагымны күр әле:
Үзенеке булган килеш
Сорый минем журналны!

Азнакай, Тымытык.



– Әле алга, әле артка
Атынып идем тагын:
Этеп җибәрегез инде –
Туктап калды бит таган!

Казан.



– Бу – Кыш бабай, бу – Кар кызы,
Ә мин... Мин – Кар бөртеге!
Бәйрәмгә киләбез сезгә,
Торыгыз көтеп бүген.

Олы Әтнә.





Ләбиб Лерон

Безнең авыл — зур авыл

Рәссам
Фәрит Муллахмәт
Шалтмылтфильм

Безнең авыл – бик зур авыл:
Йортларының чуты юк...
Каравыл өенең генә
Тәрәзендә уты юк.

Безнең авыл – бик зур авыл:
Кешеләре меңләптер...
Белгәнемне сөйлим сиңа –
Ипләп кенә тыңлап тор.



Гаҗәп хәлләр, сәер хәлләр
Безнең авылда инде:
Яңгыр кебек ява бездә
Йолдызлар көпә-көндез!



Урамнарга чыгар хәл юк –
Көн дә кызык тамаша:
Чана тартасы урынга,
Этеп йөри алаша!



Малайларны кызыктырып,
Кәҗә йөртә машина;
Ялгыш таптап китүе бар –
Чыга күрмә каршына.



Ботинканы чана итеп,
Бер тычкан сөйрәп килә...
Ике үрдәк аңа карап,
Эчләрен тотып көлә.



Кибеттән йомырка алып,
Кайтып килә бер тавык...
Бозлавыкка юлыктымы –
Тәпие китте таеп!



Сыер да тавык шикелле
Кибеткә барган бугай...
Авызы колакка җиткән –
Сөт-каймак алган бугай.



Бер абзардан ишетелә
Үгезнең җыр сузганы:
– Олы юлдан атлар килә,
Безгә кала тузаны-ы-ы...



Таң калырлык шундый хәлләр
Безнең авылда инде...
Сездә булмаган тәм-томнар
Безнең табында инде!



Үз күзең белән күрерсең,
Ышанмасаң сүзләргә.
Мин авылда булмаганда
Килеп кит бер безгә дә!



Ап-ак басуда күрерсең
Мин шыттырган борчакны...
...Бу хәлгә ышана яздым
Мин үзем дә бер чакны...



Өй тулы бака





Бакалар чыршы бәйрәмен ничек уздыра? «Боз астында, суда нинди чыршы аларга?» – дип әйтәсегезне сизеп торам. Ашыкмагыз. Казандагы 2 нче сынлы сәнгать мәктәбе укытучысы Любовь Васильевнаның өендә, чыршы янында фәкать бакалар гына. Ниндиләре генә юк аларның. Чебен хәтлеләре дә, мендәр зурлыгындагылары да бар. Каян гына килмәгәннәр: Испаниядән, Германиядән, Франциядән! Барысы 300ләп бака. Любовь Васильевна алардан күзен алалмый. Ә үзе бакчадагы Марфаны (безнеңчә Мәрфугадыр инде ул) сагына. Кызгана аны, чөнки гарип бака ул. Быел бакча күршесе аш-су әзерләгәндә, ялгыш кайнар су түгеп, аның ботын пешергән. Бичара Мәрфуга ачыргаланып кычкырган, хәтта елаган. Мәрфуга, Мәрфуга! Син кайларда хәзер? Исән-саумы? Кышны ничек чыгасың?

Любовь Васильевнаның өе тулы бака, бакчасы тулы бака. Өйдәгеләре иҗат-фантазия җимеше (байтагын үзе ясаган) булса, ә менә бакчасындагылары – чын бакалар. Ул мәхлук җаннар Любовь Васильевнаның үзләрен яратуын каян белеп алганнар диген. Югыйсә укытучы апабыз бакчада бака үрчетәм дип уйламаган да. «Зур авыз»лар үзләре килеп сыенганнар. Димәк, бака да игътибар-

га, назлы карашка мохтаҗ. Менә монысы хикмәт дисәң дә хикмәт.

Дөресен әйткәндә, без бакаларга әлләни мөкиббән түгел. Үзләрен күбрәк тискәре яктан телгә алабыз. Ыгы-зыгыны «бака туе», «бака боткасы» дип атыйбыз. «Ат дагалаганда бака ботын кыстыра», – дип тә әйтергә яратабыз.

Ә Любовь Васильевнаның нигә исе китте икән соң аларга?

– Алар бик матур, сөйкемле бит, – ди ул, – зур күз, зур авыз үзләренә килешеп тора. Ә карашлары моңсу, самими. Алар чиста сулыкларда гына яшиләр. Үзләре – бер дигән синоптиклар. Бака кычкырса, яңгыр була, җылыта. Игелекле, акыллы, сизгер җаннар алар. Гомумән, табигатьтә ямьсез җан иясе юк. Аларга күңел күзе белән дә карый белергә кирәк.

Рәссам, укытучы, 14 ел Казандагы 3 нче сынлы сәнгать мәктәбенең директоры булган ханым сүзләре бу.

Шушы көннәрдә чыршы янында тагын бер бака пәйда булды. Аны Любовь Васильевна чүпрәк-чапрактан үзе ясаган. «Марфа бу!» – ди ул. Бәй, Мәрфуга. Боты рәтләнгән. Күңеле көр. Исән-имин йөр, Мәрфуга!

Вакыйф НУРИЕВ





Рәсемнәрдә: Любовь Васильевна Куликова һәм аның дуслары.

Александр Эшкинин фотосурәтләре.

Ел, фасыл һәм гасыр

Яңа ел белән, кадерле дуслар!

Менә безнең Җир шары Кояш тирәли тагын бер кат әйләнеп чыкты. Тагын бер кыш, бер яз, бер җәй һәм бер көз үтте.

Кыш, яз, җәй, көз –болар ел фасыллары була.

Ел фасыллары бер-берсеннән ничек аерылалар? Син елның кайсы фасылын күбрәк яратасың? Ни өчен?

Җир шарына кояш тирәли әйләнеп чыгу өчен 12 ай, яки 365 көн, яки 52 атна (һәм бер көн), яки 8766 сәгать кирәк.

Гадәти календарь елда нәкъ 365 көн. Һәр 4 ел саен бер артык көн – 29 нчы февраль була. Мондый елны, кәбисә ел, диләр.

Һәр ел саен без бер яшькә үсәбез. Яшькә генә түгел, сез әле буйга да үсәсез. Бер елга күпме үскәнегезне тикшереп караганыгыз бармы? Кеше, гадәттә, 20 яшьләргә кадәр үсә. Агачлар да ел саен



үсеп тора, кәүсәләре киңәя. Кисеп алынган агач төбенә игътибар иткәнегез бармы? Анда күп түгәрәкләр була. Шул түгәрәкләргә карап, агачның ничә яшьтә булганлыгын белергә мөмкин. Һәр түгәрәк бер елны күрсәтә.

Без менә яңа 21 нче гасырның да икенче елын озатабыз. Гасырлар чигендә яшәү һәр буынга бирелмәгән. Чөнки гасыр – 100 елга бер генә килә бит. Ә без сезнең белән, гасырлар гына түгел, меңъеллыклар алмашына шаһит булдык.

Еллар, гасырлар, меңъеллыклар... эралар... Мәңгелек. Вакыт чиксез... Ләкин һәр кешегә бирелгән вакыт-гомер чикле.

Шуңа күрә вакытның кадерен белергә кирәк. Аны әрәмгә, бушка үткәрмәгез!

Һәр ел саен безнең яраткан бәйрәмнәребез кабатлана. Үткән елны исегезгә төшереп карагыз әле, бер ел эчендә Сез ни кадәр яңалык белдегез?

Илсөяр ИКСАНОВА



Рәссам Диләра НӘҮРУЗОВА



Ркаил ЗӘЙДУЛЛИН


Рәсем ясаучы тычкан

Әкият

Чинак исемле тычкан бик бәләкәй әле. Ул әбисе белән җир астындагы өйдә яши. Беркөнне аның өскә, һавага чыгасы килде. Караңгы почмакта Чинакка оекбаш бәйләп утырган әбисе: «Озак йөрмә!» – дип кычкырып калды. Чыкса... бөтен кырны ап-ак кар каплаган. Дөнья аклыкка күмелгән. Салкын. Чинак кар өстендә йөгереп йөри башлады. Әле бирегә йөгерә, әле кирегә. Аннары Чинак туктап үзенең эзләренә карады. Кар өстендә рәсем иде. Анда таулар, тау итәгендә агачлар шаулап утыра, куе үлән кайный. Үткелдән түгәрәк зур кояш чыгып килә. «Нинди матур рәсем, – дип уйлады Чинак. – Зур үскәч, мин шул тауларга китәрмен!» – Ул бу мизгелдә үзе рәссам, үзе пумала иде.

Икенче көнне тагын кар явып үтте. Ул Чинакның рәсемен дә күмеп киткән иде. «Менә яз җитәр, карлар эрер, шунда синең рәсемең да ачылыр», – дип юатты аны әбисе.

Рәсемдәге кайнап торган үләннәр арасында дуслары белән уйнар өчен Чинакка язның килгәнен генә көтәсе калды.



Рәссам Светлана ПРИВИНА

Башваткычлар



Кәҗә бәтиләре, Кыш бабай дип уйлап, ялгыш ишек ачканнар. Әмма бүрене күргә, алар кайсы кая качып беткән.

Сиңа сорау: рәсемдә ничә бәти бар һәм алар кайларга качкан?

Рәссам Илдар НӘФИЕВ

Салават күпере

11–12(152–153) — 2002

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭЛЕМТӘ МИНИСТРЛЫГЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ ҺӘМ РЕДАКЦИЯ ЖУРНАЛЫ

1990 елның март аеннан бирле чыга.

"Салават купере" ежемесячный журнал Министерства связи РТ, правления Союза писателей РТ и редакции. На татарском языке. Основан в 1990 году.

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде.

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары
Вакыйф НУРИЕВ

Җаваплы сәркатип
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Фидель ХӘСӘНОВ

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкта Ольга Покалёва рәсемнәре,

Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен.

Адрес редакции:
420012 г. Казань, ул. Муштари, 14.

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм төсләргә бүленде.

«Идел-пресс» полиграфия нәшрият комплексы» дәүләт унитар предприятиясе. Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Производствога бирелде 05.11.2002 ел.
Басарга кул куелды 05.11.2002 ел.
Кәгазь форматы 60х100 1/16.
Гарнитура – Прагматика.
Офсет ысулы белән басыла.
Тиражы 11497 данә. Заказ Б-642.
Бәясе килешү буенча.

Бәясе килешү буенча
Индекс 73953

